**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;
- Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Бүләк авылы зиратларын карап тоту (куаклар кисү, экскаватор белән агач төпләү, чүп-чар түгү);
- Бүләк авылында балалар уен мәйданчыгын урнаштыру (сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 179 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 119.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 119, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

“Сез 2021 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 250 сум күләмендә

үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;

- Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бүләк авылы зиратларын карап тоту (куаклар кисү, экскаватор белән агач төпләү, чүп-чар түгү);

- Бүләк авылында балалар уен мәйданчыгын урнаштыру (сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)”.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы М.Р.Шәрипов